БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 апреля 2022 г. № 124

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, «Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2002 елның 15 апрелендәге 02-08-01-2022 номерлы протест һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы карар **бирде:**

1. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясының 4 пунктындагы икенче абзацында «язма формада» сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: «яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында»;

1.2. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 5 пунктында «язма» сүзеннән соң «яисә электрон документ формасында» сүзтезмәсен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 1.7 статьясындагы 6 пунктында «язма» сүзеннән соң «яисә электрон документ формасында» сүзтезмәсен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 2 пунктында «язма формада» сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: «яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында»;

1.5. Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында «язма» сүзеннән соң «яисә электрон документ формасында» сүзтезмәсен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин